МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ

№ 27/о

"11" 03 2019

БОЕРЫК

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 29 декабрендәге 235/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 29 декабрендәге 235/о номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 23 апрелендәге 69/о номерлы, 2018 елның 17 октябрендәге 176/о номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы мөдире Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның «11» 03 №27/о боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 29 декабрендәге 235/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 29 декабрендәге 235/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.4 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

1 пунктчада «җиде» сүзен «биш» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктчада «җиде» сүзен «биш» сүзенә алмаштырырга;

3.4.2 пунктның өченче абзацында «өч» сүзен «дүрт» сүзенә алмаштырырга;

3.5.1 пунктның икенче абзацында «әлеге Административ регламентның 3.4.1 пункт процедурасы тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә» сүзләрен «әлеге Административ регламентның 3.4.1 пунктында каралган процедура уздырылган көнне» сүзләренә алмаштырырга;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының, дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле рәвештә министр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырыла.»;


Административ регламентка 2 нче кушымтада:

«Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озынайту турында гариза» сүзләрен «Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озынайтуга бәйле рәвештә төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза» сүзләренә алмаштырырга;

«Төзелешкә/үзгәртеп коруга 20 ___ елның «__» ________ ______ номерлы рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озынайтуны сорыйм» сүзләрен «Объект буенча гамәлдә булу срогын озынайту зарурлыгына бәйле рәвештә төзелешкә/үзгәртеп коруга 20 ___ елның «__» ________ ______ номерлы рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озынайтуны сорыйм» сүзләренә алмаштырырга;

Административ регламентка 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзүгә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта


Мөрәҗәгать итүче
Гариза һәм документлар тапшыра
Гариза, документлар
Оештыру эше һәм эш башкару бүлеге белгече
Гаризаны һәм документларны терки
Теркәлгән гариза, документлар
Бүлек белгече
Килгән гариза турында белешмәләрне Журналга кертә һәм әлеге Регламентның 2.5 п. ярашлы рәвештә документларның тупланышын тикшерә
Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре юк
Әйе
Юк
Бүлек белгече
Ведомствоара гарызнамәләр формалаштыра һәм җибәрә
Ведомствоара гарызнамәләр
Бүлек белгече
Хат әзерли һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрә яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр тапшыра
Баш тарту туры нда хат (хәбә р)
Тиешле органнар
Ведомствоара гарызнамәләргә җавап яки белемәләрнең булмавы турында хәбәр әзерлиләр
Гарызнамәләргә җаваплар
Юк
Бүлек белгече
Проект документаци-ясен тикшерә
Тикшерелгән документация
Хезмәт күрсәтүдән баш тарту нигезләре юк
Бүлек белгече
әйе
Төзелешкә рөхсәт әзерли, дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә
Төзелешкә рөхсәт, мөрәҗәгать итүчегә хәбәр
Бүлек белгече
Мөрәҗәгать итүчегә төзелешкә рөхсәт бирә
Мөрәҗәгать итүчегә төзелешкә бирелгән рөхсәт”.